НӘТИҖӘЛЕ БУЛСЫН

Татарстан белән Үзбәкстан арасы тагын да якынайды

> 2

ХАНБИКӘГӘ ХӨРМӘТ

Касыйм шәһәрендә Сөембикәгә һәйкәл ачылды

> 2

ЮКСЫНУ

Рөстәм Зәкуанны халык таныды да, зурлады да

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Чынлап уйлап карасаң, бөтен нәрсә әкият»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 82 (28855) | Шимбә | 11 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ОЧКЫЧ БУЛМАСА, ПОЕЗД БАР

Ял дигәндә, аяк идәндә! Бу мәсьәләдә адәм баласын ил-көндәге хәлләр дә, кесә ягының такыр булуы да, чир-мазар да туктатып кала алмый. Россия туроператорлар ассоциациясеннән хәбәр итүләренчә, бүген халык арасында иң популярдан саналган Төркия курортларына билетларны җәй уртасына гына алып була. Кырымга илтүче туры рейсларга билетлар инде җәй азагына да калмаган диярлек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда яшәүче Валентина Брагина да инде булмый дигәндә генә Кырымга билет эләктереп кала алган. «Казаннан Симферопольгә июньнең егермеләрендә китәрмен дип планлаштырган идем. Әмма поездга билетлар калмаган булып чыкты. Алдагы көнне мин караганда гына 50 билет бар иде. Шаккаттым. Бер тәүлек тынчу автобуста барасы булыр инде дип борчылган идем, кызым 18 июньгә бер билет табып бирде. Исән-сау йөреп кайтырга язсын инде», – ди Валентина ханым.

Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белгечләре уздырган соңгы сораштыру нәтиҗәләренә ышансаң, быел Россия халкының 7 проценты гына җәйге ялын чит илдә уздырырга җыена. Респондентларның 60 проценты исә үзебездә генә ял итәргә планлаштыруын әйткән. Рәсми саннардан аңлашылганча, быел эчке турларга сорау 35 процентка арткан. Краснодар крае, Кырым, Санкт-Петербург, Казан, Төмән һәм Мәскәү шәһәрләрендә ял итәргә теләүчеләр саны аеруча күп, ди белгечләр.

Кырым – араларында иң популяры. Мәскәүдән Кырымга туры рейсларга билетны җәй ахырына кадәр алып бетергәннәр. Кырымның туризм министры Вадим Волченко сүзләренә караганда, сорау зур булу сәбәпле, поездларга өстәмә составлар тага башлаганнар. Моннан тыш монда илтүче диңгез юлы, автобус рейслары санын да арттырганнар. Быел биредә ял итәргә теләүчеләр саны күп булса да, Кырым турларына сорау, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 20–30 процентка кимрәк, ди белгечләр. «Кырым отельләрендә бер көн яшәү уртача 2,5–2,6 мең сумга төшә. Кеше, гадәттә, анда 10–11 көн ял итә. Ике кешегә ун көнлек ял биредә якынча 50 мең сумга төшә», – ди башкаладагы туризм агентлыгы белгече Эльвира Гатауллина.

Билгеле булганча, махсус хәрби операция башлану белән Россиянең көньягына һава юллары ябылды. Аерым алганда, бүген Краснодар, Анапа, Геленджик, Ростов-Дон, Брянск, Воронеж, Белгород, Курск, Липецк, Симферополь һәм Элиста шәһәрләренә һава юлын сайлау мөмкин түгел. Россия туроператорлары ассоциациясе вице-президенты Сергей Ромашкин сүзләренә караганда, бүген күпләр Кырымга поездда яки үз машинасында баруны өстенрәк күрә. Автобус турлары исә алай ук зур кызыксыну уятмый. Күпләр автобуста сәяхәт иткәндә юлның артык озын булуыннан, автобусларның уңайсызлыгыннан зарлана. Халыкны бу транспорт төрендә юл һәлакәтенә очрау куркынычы зуррак булу да куркыта.

Әмма белгечләр июль аенда Кырымга автобуста барырга теләүчеләр саны да артыр дип фаразлый.

> Казаннан Кырымга автобус турлары бер кешегә 15250 сумнан башлана. Балалар өчен ике атналык сәяхәт 14770 сумга төшәчәк. Поездны өстенрәк күрүчеләргә плацкарт өчен – 5712, купега 9144 сум акча чыгарып салырга туры киләчәк.

Бүген Сочи отельләрендә буш номерлар юк диярлек. Хәзерге вакытта алар 80 процентка тулы, ди белгечләр. Биредәге популяр ял итү урыннарында да җәй ахырына кадәр буш урыннар юк икән инде. Россиялеләр аларга кыш азагында ук бронь ясап куйган. Белгечләр сентябрь азагына кадәр Сочи курортлары 4,5 миллион кеше кабул итәр дип фаразлый.

– Сочида өч йолдызлы кунакханәдә ике кешегә бер атна ял итү уртача 60 мең сумга төшә. Монда юл чыгымнары белән иртәнге аш кергән. Анапада исә нәкъ шундый ук шартларда ял итү уртача 42 мең сумга төшәчәк, – ди Эльвира Гатауллина. Июль аенда бу хаклар тагын бераз күтәрелергә мөмкин дип фаразлый белгеч.

Бүген россиялеләр арасында популяр булган Төркиягә билетларны да җиңел генә табам димә. Алар җәй уртасына кадәр сатылып беткән. Белгечләр Төркиядә ял итәргә теләүчеләрнең күплегеен башка илләргә чыгу мөмкинлеге чикле булу белән аңлата. Төркиядә ике кешегә ун көн ял итү уртача 150 мең сумга төшә. Бу узган елгы хаклар белән чагыштырганда 20 процентка күбрәк.

Россиянең туроператорлар ассоциациясе мәгълүматларына караганда, бүген биредәге курортларга илнең 17 шәһәреннән сигез төрле авиакомпания очкычларында барып җитеп була. Чагыштыру өчен: пандемиягә кадәр бу юнәлештә 18 авиакомпания хезмәт күрсәткән. Июньнең беренче атнасында Төркиягә Россиядән барлыгы 100 меңнән артык турист утырган 452 рейс килгән. Туроператорлар ассоциациясе белгечләре июнь азагына кадәр биредә барлыгы 500 меңнән артык россияле ял итәр дип фаразлый. Бу 2019 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 42 процентка азрак. Белгечләр моны чикләүләр аркасында бик күп кенә һава юллары, рейслар саны чикләнү нәтиҗәсе дип бәяли. Төркия курортларына сорау исә чынлыкта элеккечә үк зур, дип ышандыра алар.

«Күп кенә туроператорлар Төркиягә билетларны июль азагына кадәр үк сатып бетергән. Туристларны бәяләрнең артуы да куркытмый. Бүген алар путевкаларны теләсә нинди бәядән сатып алырга да әзер. Бүген Төркиягә юллама сораучылар саны тәкъдимгә караганда күп мәртәбә зуррак», – диелә ассоциация хәбәрендә.

РОССИЯ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Россия көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!

Сезне дәүләтебез бәйрәмнәренең иң зурысы – Россия көне уңаеннан чын йөрәктән котлыйм. Ул Туган илебезнең көчен, аның күпгасырлык тарихын, күпмилләтле халкының бөек казанышларын гәүдәләндерә.

Ата-бабаларыбызның хезмәт батырлыгыннан, яу кырындагы каһарманлыгыннан, табигатебезнең гүзәллеге һәм байлыгыннан рухланып, без игелекле, шәфкатьле гамәлләр кылабыз, мөһим ачышлар ясыйбыз һәм сөекле илебезнең көннән-көн алга барачагына ихлас өмет баглыйбыз.

Ватаныбызның рухи хәзинәләре, аның дәүләт суверенлыгын һәм бердәмлеген, кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре өстенлеген, лаеклы тормышын һәм ирекле үсешен тәэмин итүгә юнәлтелгән Россия Конституциясе принциплары һәрберебез өчен олы әһәмияткә ия.

Россия Федерациясенең алгарышлы субъектларыннан берсе буларак, Татарстан Республикасы ил куәтен ныгытуга лаеклы өлеш кертә. Сәнәгать җитештерүендәге, торакны файдалануга тапшырудагы, авыл хуҗалыгындагы, инвестицияләр җәлеп итүдәге уңышларыбыз безгә алдынгылар сафында урын тоту өчен ныклы нигез булып тора. Соңгы елларда бик күп татарстанлылар спорт, мәдәният, мәгариф һәм фән өлкәсендә, шулай ук Ватанны саклау эшендә зур җиңүләргә ирешеп, Россиянең данын арттырды. Татарстан киләчәккә өмет белән яши: көнкүрешебезнең күп кенә өлкәләрен цифрлы нигезгә кору һәм яңа технологияләр куллану безгә кадәрге күп буыннар тарафыннан тупланган эчке егәребезне, сәләтебезне тагын да нәтиҗәлерәк файдаланырга, тормыш сыйфатын яхшырту өчен халыкка хезмәт күрсәтүне тиешле дәрәҗәгә күтәрергә мөмкинлек тудыра. Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм шәхсән Президентыбыз В.В. Путинның булышлыгы үсешебезгә бәрәкәтле этәргеч бирә.

Россиягә читтән моңарчы күрелмәгән басым ясала торган хәзерге заманда гражданнарның бердәмлеген һәм үзара дус-тату яшәвен, милләтләр һәм диннәр арасындагы тынычлыкны саклау, ксенофобия һәм нацизмның теләсә кайсы яңа чагылышларына каршы көрәшү, Ватаныбызның тарихи үткәне турындагы хак мәгълүматны җиткерүгә ярдәм итү, яшьләргә күркәм тәрбия бирү – үсешебезнең мөһим шарты.

Минем уемча, Россия көнен бәйрәм итү, һичшиксез, бердәмлегебезнең ачык мисалы булыр, үз көчебезгә ышаныч өстәр.

Сезгә бәхет, иминлек, рухи күтәренкелек телим, хөрмәтле татарстанлылар!

Вазгыять

Кесә түгел, бурыч хакына

Украинага контракт буенча хәрби хезмәткә китәргә җыенучылар әнә шулай ди. Махсус хәрби операциягә үз теләкләре белән барып кушылган Татарстан егетләренең саны 500гә җиткән. Әле менә тагын дистәгә якын кешене озаттык. Үзләре белән бераз сөйләшеп алырга да җай чыкты.

«Татар-информ»

Украинада хезмәт итәргә теләк белдерүчеләргә дүрт айлык килешү тәкъдим ителә. Шунысы мөһим: егетләр шушы вакыт аралыгында элеккеге эш урыннарын саклап кала алачак. Шуңа өстәп, солдатларның үзләренә һәм якыннарына төрле ташламалар да каралган.

Контракт буенча хезмәт итүчеләрдән Татарстанда махсус батальон туплана. Аларга Россия Оборона министрлыгы түләгән акчадан тыш, Татарстан Хөкүмәте бер мәртәбә 200 мең сум күләмендә түләү вәгъдә итә. «Якташларың белән хезмәт җиңелрәк уза. Шуңа да мондый батальонны туплау – безнең өчен әһәмиятле бурычларның берсе», – дип аңлатты контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты офицеры, капитан Рөстәм Сафиуллин.

Ләкин егетләр акчадан бигрәк, бурыч үтәүнең әһәмиятлерәк икәнен әйтә. Биектаудан Павел Шевчук 23 яшен шушы көннәрдә генә тутырган. Махсус хәрби операциягә барырга теләк белдерүчеләрнең без сөйләшкәннәре арасында иң яше ул. «Чакырылыш буенча хезмәт иттем. Армиядән кайткач, товаровед булып эшкә урнаштым. Хәрби комиссариаттан контракт буенча Украинага бару мөмкинлеге булуын ишеттем. Минем бабам хәрби булган. Минем дә шул эшне дәвам итәсем килә. Үзебезнең егетләргә ярдәм итү, кулда корал тоту – минем өчен зур горурлык», – ди Павел.

Егет әби-бабасы тәрбиясендә үскән. Әбисе исән-сау. «Украинага барырга җыенуым турында ишеткәч, киңәшләрен бирде. Әле бит минем хатыным да бар. Бик борчыла инде. Тик ул миңа ышана, шуңа каршы килмәде. Үзем дә борчылам. Тере кеше бит без дә. Ләкин Ватан алдындагы изге бурычым турындагы уйлар бу курку-борчуларны оныттыра. Исән-имин әйләнеп кайтып, гаиләмне ишәйтәсем бар бит әле!» – ди ул.

29 яшьлек Эмиль Кужаковның контракт буенча хәрби хезмәт тәҗрибәсе шактый зур. Казанда туып-үскән егет 8 еллык хезмәтен Украинада дәвам итәргә тели.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Валентина МАТВИЕНКО, Федерация Советы спикеры:

Россия булганда, бер генә дәүләт тә, коалиция дә дөньякүләм хакимлеккә өмет итә алмый. Моңа дөнья беренче генә инанмый. Көнбатыш та моны аңлый. Хәзерге вакытта Россия Көнбатыш белән яшәү хокукы өчен көрәшә.

РОССИЯДӘ – ВАТАНПӘРВӘРЛЕК

Иҗтимагый фикер фонды (ФОМ) Россиядә яшәүчеләрнең ни дәрәҗәдә ватанпәрвәр булуын тикшергән. Сүз уңаеннан, 2006 елда оештырган сораштыру нәтиҗәләре белән чагыштырганда, үзләрен ватанпәрвәр дип санаучылар арткан. Ул чакта бу күрсәткеч 57 процент булган.

Спортчылар булырбыз

Россиядә массакүләм спортны үстерү буенча оператор пәйда булачак. Аның Спорт министрлыгы карамагында эшләве күздә тотыла. Президент Владимир Путин бу җәһәттән тиешле бурычлар куйган. Бурычлар исемлеге Кремль сайтында басылып чыккан.

Дәүләт башлыгы физик культура һәм спортны үстерүнең төбәкләр программалары эчтәлегенә карата тәкъдимнәрне дә раслаган. Ул шулай ук спорт клубларын оештыруны, аларны кадрлар, барлык кирәк-ярак белән тәэмин итүне йөкләгән. Бу юнәлештә башкарылган эшләр турында быел 30 сентябрьгә кадәр хисап тотарга тиешләр. Моның өчен җаваплы итеп спорт министры Олег Матыцин билгеләнгән.

Кызынасы килә!

Роспотребнадзор идарәсе быел Татарстанда 20 пляжның эшләячәге турында белдергән. Республикада биш комлыкның ял итү өчен яраксыз булуы ачыкланган. Сәбәбе – елга-күлләр суының сыйфатсыз булуы. Белгечләр сулыкларда паразитларның, вирусларның бармы-юкмы икәнен, микробиологик, радиологик күрсәткечләрен тикшерә. Чаллы, Яшел Үзән, Минзәлә, Кама Тамагы районнары һәм Казанның «Нижнее Заречье» комлыгының тиешле таләпләргә җавап бирмәве билгеләнгән. Роспотребнадзор бу комлыкларда кызыну, су коенуның тыелуы турында игъланнар урнаштыру тәкъдимнәрен җибәргән.

Ведомствода билгеләп үтелгәнчә, 1 июньгә комлыклар җәйге сезонга әзер булырга тиеш иде. Белгечләр җәй буе ком һәм суның сыйфатына күз-колак булып торачак.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

«Утрау»да яшәү бәхете,
ЯКИ БЮРОКРАТЛАРСЫЗ ТОРМЫШ КОРУ

Соңгы бер-ике көндә Россиянең мәгълүмат кырында безнең якын һәм ерак киләчәкне билгеләячәк берничә мөһим фикер яңгырады. Владимир Путин: «Ун елдан соң Россия яхшырак яшәячәк», – дигән фараз игълан итте. Кремль лидерының сүзләрен төрлечә аңларга була. Без килеп кергән менә бу матавык озакка сузылачак икән дип тә, бүген кыен булса да, киләчәктә зур перспектива көтә дип тә. «Яхшырак яшәү» дигән сүзне матди яктан тормыш җиңелрәк булачак дип аңларга кирәк. Владимир Владимирович аны нәкъ шул контекстта куллана да. Бу юлларның авторы, мәсәлән, күп кенә вакытларда кесәсендә җилләр уйнаса да, үзен дөньяның барлык олигархларына караганда да яхшырак яши дип саный. Бер нәрсәне яхшы беләм: бер генә миллиардер да минем бюджетны күтәрә алмаячак, кыядан түбәнгә сикерәчәк. Без яшибез әле: бернинди өметсезлек юк, иртәгесе көннән курку юк. Тегеләрнең исә андый тынычлыгы, ай-һай, бар микән…

Тик шулай да бу язмада без тормышның матди яклары хакында гына сөйләшербез. Нигә яшереп торырга: бу юлларның авторы да кесәдә акча күбрәк булганын, муллыкны, матди тотрыклылыкны сөя. Кем яратмый инде аны? Күпләрне үз артыннан иярткән лидер исә тормышка объектив карый бу юлы: тиз генә яхшыру вәгъдә итми, ун елдан соң да «яхшы тормыш» түгел, ә хәзергедән яхшырак тормыш фаразлый. Һәм менә анысы өчен дә, хәзергедән яхшырак тормыш өчен дә күп тырышасы бар әле. Кул кушырып утырсаң, күктән алтын яумаячак. Россия бүген «идеаль шторм» дип атала торган гадәттән тыш вазгыятькә тап булды. Дилемма менә шулай куела: сине я упкын йота, я син барлык потенциалыңны эшкә җигәсең дә калкып ярга чыгасың. Россиянең югары җитәкчелеге таныды эшнең катлаулылыгын.

Россия Президентының цифрлы һәм технологик үсеш мәсьәләләре буенча махсус вәкиле Дмитрий Песков (сүзче Песков түгел, башкасы) якындагы ун-унбиш елда «утрау» шартларында үсәргә туры киләчәген дә игълан итте. Перспективаны ул «технологик суверенитет» термины белән атады һәм бер Россия генә түгел, АКШ, Кытай һәм, бәлки, Һиндстан гигантлары да шул юлдан атлаячак дип фаразлады. Песков сүзләре белән әйтсәк, «утраулашу» «төп приоритет»ка әйләнәчәк, ягъни глобальләштерү белән саубуллашабыз. Бәхәсләшмик, андый тенденция бар. «Ватаным Татарстан»да без ун елдан артык озакламый глобальләштерүнең соңгы аккордлары яңгыраячак дип фаразлап килдек. Безнең фаразлар белән бүгенге җитәкчелекнең фаразларына туры килә икән, моңа сөенергәме, еларгамы икәнен генә әйтә алмыйбыз әлегә. Бу юлларның авторы бер генә нәрсәне искә төшерә: дөньядагы зур үзгәрешләр өчен ун ел ук вакыт калмады инде, глобаль системаны җимереп ташлау тизләнәчәк һәм «бөек борылыш» өчен күп булса биш-алты ел вакыт бар. Бу фаразыбызда без ялгыша алабыз, әлбәттә.

Бер нәрсәне искәртик: АКШ һәм Кытайның «технологик суверенитеты» Россия утравыннан бик күпкә аерыла. Боларда технологияләр, фәнни-техник куәт безнекеише генә түгел, шуңа карамастан, өскә ишелеп төшеп килүче бәла-казаларны алар да бик авыр кичерәчәк. Төп ставканы технологияләргә ясарга кирәген хәзер һәркем аңлады инде. Индонезия, әйтик, соңгы көннәрдә генә креатив белгечләрне – яңа технологияләр лидерларын магнит кебек үзенә тартуның зур программасын игълан итте. Өстенлекләр һәм бонуслар – аларга күчкән яшь белгечләрне шулар көтә. Төрекләрнең шундый юнәлештә җитди эшләре бар. Согуд Корольлеге дә шул юнәлештә тырыша. Сүз уңаеннан билгеләп үтик: ул гарәп дәүләте – бүген эчке тулай продуктның үсеше буенча дөньякүләм лидер, 9 проценттан арткан темп белән Кытайны күпкә артта калдырды. Болай да байлыклары ташып торган согудлеләрнең белгечләргә мул итеп түләргә барлык мөмкинлекләре бар.

Россиядә эш менә болайрак: рус патриоты булган һәм рус дөньясы өчен җан аткан Донбасстан килгән күп кенә ай-ти белгечләр дә, Мәскәүдә сигез елдан артык яшәүләренә карамастан, Украина паспортын Россиянекенә алыштырырга ашыкмыйлар. Газета хәбәрчесе шундый яшьләрнең берсеннән ни өчен Россия гражданлыгына күчмәвен белешкәне бар. Украина паспорты визасыз-нисез дөньяга чыгарга мөмкинлек бирә. Төп сәбәп менә шул икән. 24 февральдән соң исә Россия гражданлыгы яшьләрне тагын да ныграк чикли башлады. Дистәләгән мең яшь белгеч чит илләргә күчәргә мәҗбүр булды. Хәтта Көнбатыш илләре дә югары технологияләрдә көч түгүче белгечләрне Россиядән үзләренә тартып чыгаруның астыртын программаларын тормышка ашыралар. Россия утравын бик нык зәгыйфьләндерә ул адымнар. Тагын бер нәрсәне өстик: Россия сәнәгате җиһазларның тузуыннан интегә. Кайбер тармакларда төп фондларның (станокларның дип укыйк) искерүе 60 процеттан узып китә.

Алда китерелгән фактлар һәм саннар югарыга этелеп китү өчен плацдармның бик кечкенә, уңдырышлы туфракның бик сай булуын дәлилилиләр. Элеккечә ваемсыз булып яшәү хәзер мөмкин түгел инде. Күнегелгәнчә дәвам итсәк, бик авыр хәлдә калачакбыз. Юлдагы төп киртә – Россиядәге бюрократик аппаратның бик акрын кыймылдавы, хәрәкәтләнергә теләмәве, үзгәрешләрне яратмавы. Кремльдә моны бик яхшы аңлыйлар. Путин яшь эшмәкәрләр белән очрашканда: «Карарлар кабул иткәндә, бюрократиядән арынырга кирәк, санкцияләргә җавап шул булачак», – диде. Бик авыр һәм катлаулы мәсьәлә бу. Андый теләкләр моңарчы да күп яңгырады. Объектив булыйк: эзсез үтмәде алар. Әмма мөһимрәк проектларны тормышка ашырганда, чиновниклар диктаты үз эшен эшли әле.

Дәүләт Думасы яңа гына укытучылар җилкәсеннән бюрократик йөкне төшерү турында закон проектын беренче укылышта кабул иткән икән. Моңарчы укытучыларны кәгазь боткасыннан арындырырга вәгъдә бирмәгән бер генә министр да калмады. Әмма вазыйфаны башка лидерга тапшырганда барысы да мәгариф системасын тагын да ныграк кәгазь астында калдырып киттеләр. Вазгыять үзгәрерме, көтеп карыйк. Икътисадчы профессорларның берсе: «Базар икътисадының төп ресурсы ул – дурак», – дигән иде. Ягъни моңарчы алны-артны карамыйча куллануга исәп тоткан кешеләр тәрбияләү бурыч итеп куелды. Ул бурыч уңышлы үтәлде: җәмгыятьне кредитоманнар басты. Хәзер максатны үзгәртми булмый. Иҗтиһад итәргә, яңаны булдырырга, төзергә мотивлаштырылган яшьләр таләп ителә. Я шуңа ирешәбез, я «утрау» бата инде. Сайлау өчен ике генә юл калды.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ДУСЛЫК ОЧРАШУЫ
ТАТАРСТАН БЕЛӘН ҮЗБӘКСТАННЫ НӘРСӘ БӘЙЛИ?

Аңлашырга бик җиңел, эшләргә юнәлешләр күп. Татарстан белән Үзбәкстан арасын якынайтып, Казанда ике көнлек эшлекле очрашулар узды. Төп чара Казан Ратушасында Татарстан Президенты катнашында үтте.

tatarstan.ru

Аңа кадәр Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Үзбәкстан Закон чыгару палатасы Олы Мәҗлесенең Россия Дәүләт Думасы белән хезмәттәшлек буенча җитәкчесе, Инновацион үсеш, мәгълүмати сәясәт һәм мәгълүмат технологияләре мәсьәләләре комитеты рәисе Илхом Абдуллаев җитәкчелегендә Татарстанга килгән Үзбәкстан парламенты депутатлары белән очрашты, тәҗрибә уртаклашты.

Казан Ратушасында исә Үзбәкстан парламенты белән элемтәләр оештыру буенча Дәүләт Думасы депутатлар төркеме һәм Россия Дәүләт Думасы белән хезмәттәшлек буенча Үзбәкстан Закон чыгару палатасының депутатлары төркеме күчмә утырышы узды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та чыгыш ясады.

Сүз уңаеннан, очрашып сөйләшүнең берничә истәлекле дата алдыннан узуы да аерым мәгънәгә ия булуын искәртте Президент. Бердән, илнең төп бәйрәме – Россия көне якынлаша, икенчедән, мөселманнар өчен изге көн – җомга, өченчедән, быел Россия һәм Үзбәкстан Республикасы арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнашуга 30 ел тула. Эшлекле аралашуны бәйрәм рухы да бизи, димәк.

– Россия белән Үзбәкстан арасындагы хезмәттәшлекне үстерүдә парламентара бәйләнешләр аерым роль уйный. Үзбәкстан парламенты белән хезмәттәшлек итү буенча депутатлар төркеме составында безнең республикадан да депутатлар бар, алар да ике яклы мөнәсәбәтләрне ныгытуга үз өлешләрен кертә, – диде ул. – Күпьеллык нәтиҗәле хезмәттәшлекнең күркәм традицияләре безнең илләр арасындагы хезмәттәшлекнең ныклы нигезе булды. Бу катлаулы заманнарда безнең дәүләтләребез нәтиҗәле сәүдә-икътисади һәм мәдәни-гуманитар юнәлешләрдә эш алып баруны саклап калды.

Татарстан белән Үзбәкстан арасын товар әйләнеше дә ныгытып тора. Машина төзелеше, шиннар җитештерү, нефть юнәлеше буенча республика эш алып бара. Узган ел нәтиҗәләре буенча Татарстан – Үзбәкстан арасындагы товар әйләнеше 193 млн доллардан артып киткән. Үсеш күрсәткече – 23,5 процент. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, әле алга таба үсәргә җирлек бар. Икътисади мөмкинлекләрнең барысы да файдаланылмый, дигән фикердә ул. Бу җәһәттән эшне куәтләп җибәрергә, хезмәттәшлекне арттырырга кирәк.

– Гомумән алганда, без Үзбәкстан белән күп өлкәләрдә хезмәттәшлек үсешен күрәбез. Моны тормышка ашырыла торган проектлар, эшлекле сәфәрләр, товар әйләнеше дә раслый. Бүгенге утырышыбыз да моңа этәргеч ясар дип уйлыйм, – диде Татарстан Президенты.

Сәнәгать һәм икътисад турында гына уйлап, гуманитар өлкәне дә читтә калдырмаска. Рөстәм Миңнеханов мәдәният, фән, мәгариф, спорт, туризм юнәлешләрендә дә эшчәнлек алып барырга кирәк дигән фикердә. Ике республиканың тел-мәдәният дигәне охшаш та бит әле. Бу уңайдан Татарстан җитәкчесе:

– Үзбәк телен белгән кеше татарчаны бик тиз өйрәнәчәк. Тел бик мөһим нәрсә ул. Үзбәкстандагы коллегаларым сөйләшкәндә дә без бер-беребезне аңлыйбыз, – диде. Кунакларның кайсылары киләсе очрашуларга татарчаны да отып киләчәген әйтте.

Үзбәкстан парламенты белән элемтәләр буенча депутат төркеме аппараты җитәкчесе, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары киңәшчесе Наталия Красовская сүзләренчә, күчмә утырышның Казанда узуы да аерым мәгънәгә ия.

– Хәзерге геосәяси шартларда республикаларга дәүләтара мөнәсәбәтләрне ныгыту аеруча мөһим. Биредә җыелуыбызның максаты да шул, – диде ул.

Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфаларын башкаручы Олег Коробченко да, Үзбәкстан белән хезмәттәшлек итүнең яңа юллары күп, ди. Ул ике як өчен дә отышлы булачак. «Үзбәкстан белән күптәннән дустанә мөнәсәбәттә инде без. Берләштерә һәм охшаш итә торган сыйфатларыбыз күп. Җиңел сәнәгать, белгечләрне өйрәтү, машина төзелеше, нефть җитештерү һәм эшкәртү кебек юнәлешләрдә эшчәнлек алып барыла. Үзбәкстанда Менделеев таблицасындагы барлык элементлар да барлыгын онытмыйк. Безгә бергәләп эшләргә кирәк. Ул эшчәнлек ике як өчен дә отышлы булсын. Үзара тәҗрибә, белгечләр белән уртаклашу мөһим. Туризм юнәлешенең дә зур үсештә булуын билгеләп үтәсе килә», – диде ул.

* * *

Республиканы көчле итүчеләр. Президент төбәк үсешенә зур өлеш кертүчеләргә республика һәм федераль дәүләт бүләкләрен тапшырды. Казан Кремлендә узган тантана Россия көненә багышланган иде.

– Без меңьеллык тарихы һәм бай мәдәни мирасы булган илдә яшәвебез һәм эшләвебез белән горурланабыз. Күп буыннарның нәтиҗәле хезмәте, федераль үзәк һәм шәхсән Россия Президенты Владимир Путин ярдәме белән безнең республика илнең алдынгы төбәге булып тора, – диде Татарстан Президенты. – Без сезнең белән горурланабыз. Сезнең сәләтегез, хезмәт сөючәнлек, нык һәм батыр булуыгыз республикабызны көчле итә.

* * *

Рөстәм Миңнеханов Грозный шәһәре мэры Хас-Мөхәммәт Кадыйров белән очрашты. Грозный делегациясе башкалага берничә юнәлеш буенча Татарстан тәҗрибәсен өйрәнер өчен килде. Бу – торак-коммуналь хуҗалык системасы эше, торак төзелеше, сәнәгать һәм икътисад үсеше.

Казан Кремлендәге очрашуда Рөстәм Миңнеханов Кадыйров белән хезмәттәшлек юнәлешләре, сәүдә-икътисади элемтәләрне үстерү һәм уртак проектлар турында сөйләште.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:
«ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ДИНЕ БАР, КЕШЕНЕ ХӨРМӘТ ИТӘРГӘ КИРӘК»

Билгесез кешеләр Актаныш зиратында урнашкан кабер өстендәге хачны кабат кискәннәр. Район башлыгы Энгель Фәттахов бу очракны провокация дип атады һәм җаваплылыкны үз өстенә алуын белдерде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, гаепле кешеләр үз гамәлләре өчен җавап тотарга тиеш, диде.

«Бүген безнең җирле зират территориясендә Чаллы кешесе, әмма безнең районда теркәлгән Виктор Смирновның каберен янә мәсхәрәләделәр. Беренче очрак узган елның декабрендә булды һәм җәмгыятьтә зур шау-шу чыгарган иде. Бу – провокация. Әлеге коточкыч очракны булдырмый кала алмавыбыз өчен мәрхүмнең туганнары һәм якыннарыннан гафу үтенәм. Җаваплылыкны тулысынча үз өстемә алам, моның өчен җавап тотарга әзермен һәм отставкага бирәм», – дигән Энгель Фәттахов. Әлеге белдерү Актаныш районының рәсми сайтында урнаштырылды.

Хөкүмәт йортында узган утырышта Татарстан Президенты әлеге хәлгә карата үз фикерен җиткерде.

– Безнең җәмгыятьтә мондый хәлләр булырга тиеш түгел. Без төрле милләт һәм дин кешеләрен хөрмәт итәргә гадәтләнгән. Гаеплеләр, һичшиксез, ачыкланырга һәм үз гамәлләре өчен тулы җаваплылык тотарга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент район һәм шәһәр башлыкларына бу мәсьәләгә игътибар белән карарга һәм мондый очракларга юл куймаска кушты. «Бу нормаль хәл түгел. Безнең республикага хас күренеш түгел. Теләсә кайсы динне хөрмәт итегез. Һәркемнең үз дине бар, кешене хөрмәт итәргә кирәк», – диде ул.

Һәрвакыт тәртип һәм тотрыклылык үрнәге булган Актаныш районы өчен бу гомумән матур күренеш түгел, дип искәртте Президент.

Виктор Смирнов кабере өстендәге хачны узган ел ахырында да кискәннәр иде. Ул вакытта җинаять эше кузгатылды, Рөстәм Миңнеханов район башлыгы Энгель Фәттаховка каты шелтә белдерде.

Кыр эшләре тәмам

Эше тәмам, уңыш көтәләр. Татарстанда 1,8 млн гектар сабан җире чәчелде. Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров кыр эшләренә нәтиҗә ясады.

Министр әйтүенчә, 1,575 млн га мәйданда зарарсызландыру чаралары үткәрелгән (шуларның 795 мең га – чүп үләннәргә, 268 мең га – төрле авыруларга, 162 мең га – корткычларга каршы).

Кыр эшләре белән бер рәттән терлек азыгы әзерләү дә бара. Быел 3,2 млн тонна сенаж, 3,7 млн тонна силос һәм 350 мең тонна печән әзерләргә кирәк. Бу эштә Әлки, Яшел Үзән, Саба, Түбән Кама, Зәй, Актаныш, Нурлат, Алексеевск районнары активлашкан инде. Агрофирмалар да кушыла.

Тармак башлыгы фермерлык юнәлеше үсеш алуын әйтте. Теләче, Әгерҗе, Кукмара, Саба, Яңа Чишмә, Мамадыш, Биектау районнарында баш саны арткан. Ә менә Аксубай, Зәй, Лаеш, Мөслим, Ютазы, Лениногорск районнарында мөгезле эре терлек саны кими икән.

Сүз уңаеннан, 2019–2021 еллар арасында хуҗалыкларның кече формаларына матди ярдәм күрсәтү өчен 3,1 млрд сум күләмдә акча бүлеп бирелгән. Грант программаларында соңгы өч елда Кукмара, Саба, Тукай районнарында эшләүче фермер һәм кооперативлар аеруча актив.

Марат Җәббаров «Минем субсидияләр» системасы турында да искә төшерде. Әлеге система аша инде икенче ел шәхси ярдәмче хуҗалыкларга (ЛПХ) субсидияләр бирелә. Май башында аның буенча 50 мең кеше акча алган.

Чыгышын йомгаклап, Марат Җәббаров күңелле яңалык та җиткерде. Кукмара районы хезмәтчәннәре республика тарихында беренче тапкыр тәүлегенә 400 тонна сөт савып алуга ирешкән.

dumrt.ru

Мәгъруp ханбикә

Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачылды. Ул Касыйм шәһәренең Хан мәчете һәм Шаһ Гали төрбәсе янында урнашкан, Сөембикә хөрмәтенә аталган скверда урнаштырылган.

Һәйкәл ачу чарасы Идел буе Болгары халыклары тарафыннан ислам динен рәсми кабул итүгә – 1100 ел, Касыйм шәһәренең 870 еллыгына, шулай ук Россия халыкларының мәдәни мирасы елы уңаеннан оештырылды. Тантанада Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Рязань өлкәсе Хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Анна Рослякова һәм башка кунаклар катнашты.

Өч метр биеклектәге, 1,5 тонна авырлыктагы скульптура Петербург остаханәләрендә бронзадан коелган. Равил хәзрәт Гайнетдин әлеге монументны зур батырлык, намуслылык символы дип атады. «Сөембикә һәйкәле – ул зур батырлык, намуслылык символы, фән һәм сәнгать яклы хатын-кызга һәйкәл. Шулай ук ул үз халкына тугрылыкка, аның киләчәге өчен үз тормышын корбан итәргә әзер торуга куелган һәйкәл», – диде Равил хәзрәт Гайнетдин.

Васил Шәйхразыев Россиянең көче – бердәмлек һәм үзара аңлашуда дип белдерде. «2010 елдан борынгы Болгар шәһәрен торгызу буенча эш башланды. Быел 21 майда анда Идел Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны билгеләп үттек… Без бөтен дәүләт, дини бәйрәмнәргә бер-беребезгә кунакка йөрешәбез, котлашабыз, бергә шатланабыз. Дус булмаган илләр безнең тарихи һәйкәлләребезне җимергәндә, без тагын бер кат үз тарихыбызны яратуыбыз һәм кадерләвебезне күрсәтәбез. Сөембикә һәйкәлен ачу да – шуның мисалы», – диде ул.

Милли Шура рәисе проектны хуплаган Касыйм шәһәре халкына, Рязань өлкәсе һәм шәһәр җитәкчелегенә, Равил хәзрәт Гайнетдингә, Рязань өлкәсе татарларының төбәк милли-мәдәни мохтарияте рәисе Илдар Бикуевка рәхмәтен җиткерде.

Бүгенге тарих фәнендә Сөембикәнең туган һәм үлгән даталары төгәл билгеле түгел. Кайбер чыганакларда ханбикәнең 1557 елда Касыйм ханлыгы җирләрендә вафат булып, шунда җирләнүен күрсәтәләр.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышын 2022 елның 15 июнендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 8 июне
№ 1451-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. О.В. Коробченконы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп куюны килештерү турында.

3. Коробченко Олег Владимировичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составына һәм Кеременәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында.

5. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 11 маендагы 13 номерлы килешүне раслау хакында.

6. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Башкортстан Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 31 маендагы 17 номерлы килешүне раслау хакында.

7. «2021 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 298-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «2021 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 299-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 308-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 305-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. 2021 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап.

12. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 286-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

13. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 307-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 306-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 301-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 295-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 296-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 300-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 303-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

21. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 304-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

22. «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 297-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 64 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.

24. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы турында.

25. «Георгий тасмасы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 109180-8 номерлы федераль закон проекты турында (Георгий тасмасының статусын билгеләү хакында).

26. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 119762-8 номерлы федераль закон проекты турында (сатып алуны бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) гамәлгә ашыру өлешендә).

27. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 115273-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары тарафыннан кредит оешмаларында счетлар ачу мөмкинлеге хакында).

28. «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешенең 3.1 – 3.5 пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 104089-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең маркировкалау өлкәсендәге вәкаләтләрен туктатып тору өлешендә).

29. «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 121564-8 номерлы федераль закон проекты турында.

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.3 һәм 23.79 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 106447-8 номерлы федераль закон проекты турында (федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре башкарма хакимияте органнарының административ хокук бозулар турындагы аерым эшләрне карау вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).

31. «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль законның 11 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 76992-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашуына кагылышлы аерым юридик-лингвистик һәм мәгънәви төгәлсезлекләрне бетерү өлешендә).

32. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 29 статьясына үзгәреш кертү хакында» 127048-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хезмәт үтүче затларның физик әзерлеген оештыру тәртибен камилләштерү өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 8 июне
№ 1452-VI ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

09 июнь, 2022 ел Казан ш. № 172/1519

Бер мандатлы сайлау округлары буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә гражданнарның сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 71 статьясындагы 8 пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының104 статьясындагы 1, 2 өлешләренә туры китереп, «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Вольфсон Илья Светославовичның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» 25 октябрь, 2021 ел, № 1149-VI ГС, «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Нуриев Марат Абделхәй улының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» 25 октябрь, 2021 ел, № 1151-VI ГС Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округында, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округында бер мандатлы сайлау округлары буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны 2022 елның 11 сентябренә билгеләргә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Бу карарны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П.Борисова

Бурыч хакына

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– ДНР һәм ЛНРдагы вакыйгалар турында көн-төн сөйлиләр. Тыныч кына тыңлап, читтән күзәтеп тора алмыйм башка. Физик һәм рухи яктан мин әзер, – ди Эмиль. – Хатыным һәм дүрт яшьлек улымны калдырып китәм. Минем карарыма каршы килүче булмады. Әни, гомумән: «Улым, барырга вакыт җиткәндер», – диде. Шөкер, гаиләбез матди яктан тәэмин ителгән. Ягъни акчасына кызыгып бармыйм анда. Үзебезнекеләргә булышырга кирәк!

Әлмәттә яшәүче Александр Мельниковка 34 яшь. Таза-сау ир-ат була торып, Украинадагы вакыйгаларны өйдә ятып, телевизор аша гына күзәтә алмыйм, ди ул.

– Хатыным, биш балам бар. Өчесен тәрбиягә алып үстерәбез. Алар минем карарны ничек кабул итте дисезме? Ихтирам белән. Хатын да: «Үзең өчен хәл иткәнсең икән, бар», – диде. Әти-әнием дә каршы килмәде. Ләкин күрәм, сизәм инде: бик нык борчылалар. «Исән-сау әйләнеп кайта күр – калганы мөһим түгел», – диделәр. Ничек кенә булмасын, мин үз бурычымны үтәргә барам. Бер гаепсез кешеләрнең гомерләре өзелгәнен тыныч кына күзәтә алмыйм», – дип сөйләде ул безгә.

Капитан Сафиуллин сүзләренчә, Украинада контракт нигезендә хезмәт итәргә теләк белдерүчеләрнең саны бик күп. «Көн саен 10лап гариза кабул итәбез. Аларның һәркайсы тикшерелә. Килешү төзергә җыенучыларның яше 50 яшькә кадәр булырга, икенчедән, ул я чакырылыш буенча хәрби хезмәт узарга, я югары яки урта белемле булырга тиеш. Моннан тыш, гариза бирүчеләр тикшерүләр узарга тиеш була. Бу – медицина, психологик-психиатрия тикшерүе, уку, эш һәм яшәү урыны турында мәгълүматлар. Бурычлы, хөкем ителгән егетләр төшеп кала. Алар бит – Ватаныбызның йөзе», – ди ул.

Контракт төзүчеләрнең күбесе – 30 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар. «Яшь егетләр азрак. Күпчелеге – Чечня, Сүриядәге вакыйгаларның шаһитлары. Ягъни хәрби операциянең нәрсә икәнен яхшы белүчеләр», – дип аңлатты капитан.

Казанда контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты башлыгы, майор Евгений Токмаков сүзләренчә, хәрби килешү төзүчеләр арасында хатын-кызлар да бар. «Алар күбесе медицина яки сәнгать өлкәсендә эшли. Беренчесе аңлашыла инде. Ә музыкаль белеме булганнар махсус хәрби оркестрларда эшли ала», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен полиция полковнигы **Айдаров** Марат Илдар улы; намуслы хезмәтләре, җәмәгать тәртибен саклаганда кыюлык һәм батырлык белән гамәл кылганнары өчен Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе «Тайфун» аерым билгеләнештәге мобиль отрядының 2 нче оператив ротасы 2 нче оператив взводы командиры, полиция өлкән лейтенанты **Трехонин** Владимир Владимирович; Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең «ТИМЕР БАТЫР» тиз гамәл йөртүче махсус отряды командиры урынбасары, полиция полковнигы **Угахин** Александр Аркадьевич; Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе «ТИМЕР БАТЫР» тиз гамәл йөртүче махсус отрядының 1 нче хәрби бүлекчәсе полицейские (машина йөртүче), полиция прапорщигы **Хәмзин** Рамил Рәфхәт улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«НПО Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте слесаре-ремонтчысы Гыйззәтов Марат Нәкыйп улына, «Охтин-Ойл» ябык акционерлык җәмгыятенең нефть промыселы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча мастеры **Иванов** Николай Ильичка, «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы нефть промыселы башлыгы **Садрыев** Айрат Фәрит улына, «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы нефть промыселы катлам басымын саклау участогы мастеры **Сәхәпов** Илшат Тәгъзим улына, «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы нефть промыселы нефть һәм газ чыгару операторы **Чуриков** Евгений Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Азнакай шәһәре Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең эшкә урнаштыру һәм махсус программалар бүлеге әйдәүче инспекторы **Газизова** Рузилә Мөхәммәт кызына; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Камаев** Александр Михайловичка; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чүпрәле муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Йосыпова** Зөлфия Иршат кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опека» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе социаль хезмәткәре **Ногманова** Гүзәлия Нәфис кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль хезмәткәре **Осипова** Зелена Дмитриевнага, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алабуга муниципаль районындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль хезмәткәре **Фатыйхова** Сәрия Камил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казметрострой» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: җир астында тулы көн эшләүче участок маркшейдеры **Головинская** Надежда Сергеевнага, слесарь-ремонтчы **Патрин** Виктор Алексеевичка, җир асты участогы механигы **Шамыкаев** Андрей Алексеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең әйләнә-тирә мохитне саклау буенча әйдәүче инженеры **Кутузова** Татьяна Викторовнага **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Әкбәрова** Фирая Барый кызы; халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Галиәхмәтов** Марат Әгътәс улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Чистайның чәчү орлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Прокофьев** Николай Петрович; халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Зеленодольскиның психик авыруы булган гражданнар өчен интернат-йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе социаль-тернәкләндерү бүлекчәсенең мәдәни чаралар оештыручысы **Садыйкова** Нурия Әкрәм кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен шәхси эшкуар **Хәкимов** Хәмит Габделхәй улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Галиуллина** Альмира Кәниф кызы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе **Мөгыйнов** Хәким Сәгыйть улы, Татарстан Республикасы Балтач район советы аппараты җитәкчесе **Мөхәммәтҗанова** Рәзинә Хөрмәтулла кызы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы **Сөнгатуллин** Рафис Равил улы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы **Тимофеев** Виталий Григорьевич **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасының Лениногорск шәһәреннән җиде бала (алтысына өч яшь тулган) анасы **Лобанова** Елена Анатольевна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Әхмәтов** Разил Латыйп улы, хезмәт ветераны **Вәлиев** Нәкыйф Фатыйх улы, хезмәт ветераны **Вердиев** Агаҗан, хезмәт ветераны **Гафуров** Таһир Гафур улы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция полковнигы **Салеев** Владимир Сергеевич, хезмәт ветераны **Фәрзиев** Фәрид Хәбибулла улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы хезмәтенең «Каенлы» бүлекчәсе агрономы (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Афзалов** Раил Фәиз улына, Тимирязев исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Ганиев** Азат Мәгъфур улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Ныртү» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе (Татарстан Республикасының Саба районы) **Гаялетдинов** Назыйм Шамил улына; «Агро Л» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бозау караучысы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Зайцева** Наталья Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Промочистка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәчесе урынбасары (Нурлат шәһәре) **Анисимов** Анатолий Егоровичка, «Савиново 81» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авария-диспетчерлык хезмәте диспетчеры (Казан шәһәре) **Белозерова** Татьяна Николаевнага, «Саба районының Шәмәрдән күптармаклы торак-коммуналь хуҗалык производство предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыятенең ассенизация машинасы йөртүчесе **Ибраһимов** Фидаил Биктимир улына, «Буа җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте баш инженеры **Насыйбуллин** Марат Мөнир улына, «Әлмәт-Водоканал» акционерлык җәмгыятенең канализация челтәрләре һәм КНС участогы башлыгы **Шәйхетдинов** Ризван Хәмидулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Чишмә» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Әхнәпов** Әнис Әхсән улына, «Кама аръягы-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Ногманов** Радик Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Нур Баян исемендәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Гарифҗанова** Ләйсән Фәис кызына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2 нче бүлекчәсе бройлер цехы башлыгы (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Камалиев** Марсил Хәбри улына, «Мамадыш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе баш бухгалтеры **Нуриев** Альберт Наил улына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 3 нче бүлекчәсе бройлер цехы кошчысы (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Шашкина** Дарья Николаевнага; «Мәңгәр» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Мостафин** Тәлгать Габдулхак улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесе башлыгы урынбасары (шәхси состав белән эшләү буенча), полиция полковнигы **Хөснетдинов** Ринат Наил улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе клиент хезмәтләре эшчәнлеген оештыру идарәсенең Кайбыч районындагы клиент хезмәте (бүлек хокукында) җитәкчесе **Зиннурова** Гөлчәчәк Мингәрәй кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Билбаулы көрәш һәм көрәш спорт федерациясе» Әстерхан төбәк иҗтимагый оешмасының башкарма директоры **Әюпов** Нәзир Хәдилбәк улына; Казан шәһәренең «Ишкәкле спорт төрләре буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Герасимов** Игорь Алексеевичка; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе директоры **Рәхмәтуллина** Мөнирә Таһир кызына; «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте «Нефтехимик» спорт клубы учреждениесенең җиңел атлетика буенча тренеры **Сандимиров** Геннадий Дмитриевичка; «Чаллы технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең физик тәрбия җитәкчесе **Федоров** Денис Михайловичка; Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «АЛТЫН АЛКА» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Яраханов** Ирек Вазыйх улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Белдерү

Кадастровым инженером Соловьевым Дмитрием Николаевичем (423803, Республика Татарстан, г. Набережные Челны, пос. ЗЯБ, ул. М. Жукова, д. 23, sden@newmail.ru; контактный телефон: 8-937-598-19-61) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:28:000000:294, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Мензелинский муниципальный район, Наратлы-Кичуское сельское поселение. Заказчиком работ является Баянова Гульфира Закиевна (423800, Республика Татарстан, г. Набережные Челны, ул. Ш.Усманова, д.27, кв.137; контактный телефон: 8-937-296-67-96). С проектом межевания земельных участков можно ознакомиться в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения, а также предоставить в письменном виде обоснованные возражения и предложения о доработке проекта межевания относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли или земельных долей земельного участка, по адресу: 423803, Республика Татарстан, г. Набережные Челны, пос. ЗЯБ, ул. М. Жукова, д. 23, офис ООО «Меридиан».

Кадастр инженеры Соловьев Дмитрий Николаевич (423803, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ЗЯБ бистәсе, М. Жуков урамы, 23 нче йорт, sden@newmail.ru; телефон номеры: 8-937-598-19-61) Татарстан Республикасы, Минзәлә районы Наратлы Кичү авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, 16:28:000000:294 кадастр номеры астындагы җир биләмәсенең җир өлешләре исәбенә бүленеп бирелә торган җир биләмәләренең чикләрен билгеләү проектын әзерләде. Заказ бирүче – Баянова Гульфира Закиевна (423800, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов ур., 27 нче йорт, 137 нче ф.; телефон номеры: 8-937-296-67-96). Җир биләмәләренең чикләрен билгеләү проекты белән бу рәсми хәбәрне бастырганнан соң 30 көн эчендә танышырга була. Шулай ук дәлилләнгән каршы килүләр һәм җир биләмәләренең чикләрен билгеләү проекты буенча, җир өлеше яки җир өлешләре исәбенә бүленеп бирелә торган чикләрнең үлчәме һәм урнашуына карата эшләрне тәмамлау турында тәкъдимнәрне түбәндәге адрес буенча язмача бирергә була: 423803, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ЗЯБ бистәсе, М. Жуков урамы, 23 нче йорт, «Меридиан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте офисы.

Студенческий билет, выданный Казанским государственным энергетическим университетом от 01.09.2018 г. № 2180147 на имя **Султанова Рината Фаниловича**, в связи с утерей считать недействительным.

Язучы фикере

Әкият

Йоклый алмый ятам. Күзләрне йомып, тән изри башлауга ук әллә каян гына сискәндергеч бер тойгы пәйда була да бөтен тәнне тартыштырып куя. Күңелне шом баса. Әллә шом, әллә моң инде ул, аңламассың. Ямансу инде ничектер. Җанда әйтеп бетергесез сагыну бар. Тик мин нәрсәне сагынганлыгымны гына аңлый алмыйм.

Сабый чакта рәхәт булган икән. Ул чакта бик йокы килми бит инде. Кичен дә, иртәсен дә. Мин әле үземне бот буе гына чагымда көн саен көтү куарга торганымны хәтерлим. Үзем кумыйм инде ул көтүне, барысын да әни эшли. Мин аяк астында буталып кына йөрим. Шунда күршеләрнең берсе мине үсендерергә теләп әйтеп куйды:

– Менә, ичмаса, маладис малай. Көн дә әнисенә көтү куыша.

Минем түбә күккә тияргә дә өлгермәде, икенче күрше бәреп төшерде:

– Йөрсен, әйдә, файдалары тия башлагач, уятып та булмый аларны.

Хәзер беләм инде, ул хаклы булган. Файдаң тия башлагач, чынлап та, йокыдан уяну авырая икән. Торасы килми. Йоклыйсы килә, ә йоклатмыйлар. Хәзер менә комачау итүче дә, кырык тарафтан чакырып торган эш тә юк, ә йокы табалмыйча интегәм. Йоклыйсы иде бер…

Сабый чакта йокларга теләмәсәк, әкият сөйләп йоклаталар иде. Ягымлы тавыш талгынга гына мавыктыргыч бер әкият сөйли. Син тыңлап ятасың. Кызык. Әкият дөньясына кереп чумасың, ара-тирә сораулар бирәсең. Сиңа кыска гына җаваплыйлар да тагын сөйли башлыйлар:

– Тарталар, тарталар, тартып чыгаралмыйлар, ди. Шуннан әби оныгын чакырган…

Син әкият дөньясына күчеп, хыял диңгезендә йөзә башлыйсың һәм бер арада үзең дә әкияткә әйләнеп, әвен базарына күчәсең. Рәхәт. Йокы да татлы була.

Хәзер әкият сөйләп йоклатучы юк. Аптырап телевизор кабызасың… Ә анда… Юк, анда да туктаусыз рәвештә әкият сөйлиләр инде, бер карасаң. Тормыш шартлары яхшыра, хезмәт хаклары арта, гомер озынлыгы күбәя, диләр. Матур әкият! Һәм берсе дә ялган түгел… бер карасаң… Тормыш шартлары чынлап та яхшыра бит инде. Шартлар көннән көнгә әйбәтрәк булып күренә. Тормыш үзе генә элеккечә кала. Элек тә бер нәрсә дә җиткереп булмый иде, әле дә шулай. Хезмәт хаклары да көннән көнгә арта. Шулайдыр. Ышанырга кирәктер. Телевизор тиклем телевизор башы белән адәм алдап утырмый торгандыр бит инде ул. Арзанлы телевизор булса, бәлки, алдар да иде әле, юк, ул бит илле меңлек яхшы җайланма. Былтыр илле мең иде, хәзер андыйлар йөздән дә ким түгел. И, дәрәҗәсе күтәрелә инде хәзер телевизорның. Гомумән, бөтен нәрсәнең дә дәрәҗәсе күтәрелә. Телефонның да, машинаның да… Азык-төлекнеке дә. Хәтта сөт тә өч ай элек алтмыш сум иде, хәзер – йөз. Хәтта тавык йомыркасы да… Тирә-якка күз салсаң, бөтен әйбернең дә абруе күтәрелә. Шулай булгач, хезмәт хаклары да бер урында гына тора алмый бит инде. Ул да арта торгандыр. Телевизор алдашмый. Ул бит тәгаен генә: «Фәлән кешенеке арта», – дими. Димәк, кемнекедер арта. Кемнекедер, кайдадыр, ничектер арта. Телевизор бит ул кеше турында сөйләми, ул ил турында сөйли. Илнең хәле яхшы, димәк. Шуңа күрә кешенең гомере дә озыная бара. Элек кенә ул ирләр алтмыштан пенсиягә чыгып, алтмыш биштә үлеп китәләр иде. Ә хәзер алай булмый. Телисеңме-теләмисеңме, алтмыш җидегә кадәр яшәргә кирәк. Шуннан пенсиягә чыгарга һәм ким дигәндә биш ел яшәргә… Ну ярый, өч ел инде… Ну ярый… Ләкин пенсиягә чыгу әбизәтелне! Ватан алдындагы бурычыңны үтәп китәргә кирәк. Чөнки җирләр алдыннан мулла бабай: «Бу кешенең берәүгә дә бурычы калмадымы?» – дип сорый. Ә синең бурычың калса? Ватаның алдында? Алла сакласын инде…

Көнозын безгә әкият сөйлиләр икән. Әле бер көнне күршедәге Хәтмулла бабай рекламадан күреп, бил авыртуын баса торган дару алып кайткан. Кыйммәт дип тормаган инде, бик әйбәт, дигәч. Кайтышлый ук кереп мактанды. Чынлап та, малай, бераздан тәрәзәгә күзем төшсә, Хәтмулла картың ихатасында очып кына йөри. Файдасын тапкан. Аягы җиргә дә тими, әле анда бара, әле монда. Метеор! Минем дә бил артык ныклы түгел, исемен язып алыйм әле дип кергәч кенә белдем, Хәтмулла картның бил сызлавы басылмаган, эче генә йомшарган икән. Рекламасы да әкият инде аның. Чынлап уйлап карасаң, бөтен нәрсә әкият. Көне-төне безгә әкият сөйлиләр. Матур әкият. Без үзебезне әкият каһарманнары итеп тоеп, шул әкият илендә яшибез. Шушы әкиятне тулыландыра, баета, тагын да хәйранрак итә торган гамәлләр кылабыз. Шул гамәлләребез өчен макталабыз да түбәбез күккә тия, үзебезне тагын да көчлерәк, гайрәтлерәк, мәһабәтрәк итеп хис итәбез. Рәхәт!

Тик нигәдер йоклап кына булмый.

Марат КӘБИРОВ

ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ

барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара

ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.

Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.

Пенсионерларга 15-20% ташлама!

Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре h.б.

Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!

тел.: 8 905 199 99 79

Реклама

Газетаның киләсе саны 15 июньда чыга

МӘҢГЕЛЕКТӘ КИЛӘ КАЛАСЫ...

Май ахырында Арчаның Симетбаш авылына чакырдылар. Клуб мөдире Зилә Шәрәфиева шалтыратты. «Якташыбыз Рөстәм Зәкуанны искә алу кичәсе үткәрәбез, кайта алырсың микән?» – ди. Ничек кайтмыйм ди инде! Тик менә «якташыбыз Рөстәм» диюе генә бераз аптыратты. «Бәй, Рөстәм Азнакайныкы бит ул», – дим.

«Азнакайныкы да», – дип кенә куйды Зилә. Рөстәм аны Симетбашның «старостасы» дип йөртә һәм Зиләгә мондый вазыйфа бик ошый иде бугай. Чөнки авылда нинди генә эш башланса да, оештыру мәшәкатенең шактые аның җилкәсенә төшә иде. «Староста» дигән сүз тәки ябышып калды бугай Зиләгә, телефоннан шалтыратып: «Староста, ни хәлләр сездә?» – дип соравыма бер дә аптырамый ул.

Якташлыкка килгәндә, арчалылар Рөстәмне үз кеше санап, «безнең Зәкуан» дип йөрттеләр. Шуңа күрә 61 яшендә бакыйлыкка күчкән Рөстәм Зәкуановны искә алу кичәсенең Арчада узуы табигый. Өч авыл – Симетбаш, Кышкар, Кишет авылларының клубта, китапханәдә эшләүче кызлары үзләре оештырган иде бу кичәне. Аңа «Мәңгелектә килә каласы» дигән исем дә кушканнар. Кишет кызы Надия Йосыпова кичәне иң әүвәл үзләрендә уздырырга ниятләгән, әмма Симетбаш ягына күңеле тарткан. Ни дисәң дә, шушы авылда Рөстәм тагын бер нигез корган иде. Симетбашның, арчалылар әйтмешли, легендар егете Лотфулла Шәфигуллин Рөстәмгә: «Пенсиягә чыккач, гаиләң белән безнең авылда яшәрсең, калган гомерне бергә үткәрербез», – дигәнрәк сүзләр әйткән булган. Кредит алып, йорт салды Рөстәм Симетбашта, тик анда яшәргә генә насыйп булмады.

Заманында «Таттелеком» элемтә оешмасын җитәкләгән Лотфулла Нурислам улы белән эшләгән еллары Рөстәм тормышында аерым урын алып тора. Татарның тарихын, мәдәниятен-сәнгатен, күренекле шәхесләрен халык хәтеренә уеп калдыру өчен ни генә эшләмәделәр алар?! Җиде музей гына ачтылар һәм бүген җидесе дә матур гына эшләп килә. Истәлек ташлары кую, чишмәләр ачу һәм төзекләндерүне санап та тормыйм.

Иске Кишет егете, Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин нигезендә менә дигән музей ачтылар алар. Дөресен әйткәндә, Герой инде әкренләп онытыла бара иде. Бүген Арча хәрби комиссариаты аша армиягә алынучылар Герой нигезеннән ватанны сакларга китәләр. Сугыш ветераннары, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан солдатлар да еш килә монда. Рәсми тел белән әйтсәк, яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшен «Таттелеком»ның элекке хезмәткәре, запастагы полковник Рөстәм Гомәров һәм хәрби комиссар Алмаз Борһанов алып бара. Әлеге шәхесләрнең исемнәрен махсус телгә алам, чөнки халык хәтеренең никадәр озын (йә кыска) булуы аерым кешеләргә бәйле. Мин аларны бер дә икеләнмичә, «фидакарьләр» дияр идем. Дәрдмәнднең:

«Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида», –

дигән шигъри юллары кайчак алар турында язылган кебек булып китә.

Рөстәм Зәкуанны соңгы тапкыр күрүем искә төште. Яман авыру үзенекен иткән – йөзе сары иде инде аның. Тик сер бирмәскә тырыша. Хатыны Гөлфәния дә: «Миллиметрлап булса да алга барабыз, Риман абый», – диде.

Моны күңел юату өчен әйткәне аңлашыла иде. Хәер, ул вакытта ниндидер могҗизага үзем дә ышанган идем. Рөстәм дә: «Абзый, бер операциягә кереп чыгасы калды, башкарасы эшләр муеннан, бергәләп эшләрбез», – дигән иде. «Бергәләп эшләү» дигәне минем әлеге егетләрнең изге гамәлләре турында газета-журналлар өчен язмалар әзерләү инде. Әмма операция өстәле дустым Рөстәмнең гомер юлында соңгы станса булган икән.

Симетбашта узган кичәдә чакырып китергән кешеләр юк иде, барысы да Зәкуанны ихлас яратканнар, хөрмәт иткәннәр. Аларның истәлекләрендә яңадан терелде Рөстәм, әйтерсең лә үзе дә шунда утыра иде. Вакыты-вакыты белән тирә-ягыма карап, сискәнеп тә киткәләдем. Үзем гел «Мәңгелектә килә каласы» дигән сүзләр турында уйландым. Бу шигъри юлларны язганда, Рөстәм күркәм эшләре белән мәңгелектә калу турында хыялланмагандыр, әлбәттә. Тамак кырып, мыек борып, күкрәк сугып йөрү аңа, гомумән, хас түгел иде. Лотфулла Нурислам улы да, Рөстәм дә һәр эшкә: «Моны кемдер башкарырга тиеш бит инде», – дип тотындылар.

Аларга карап күпләр сокланды, әмма «акчалары күптер» диючеләр дә булды. Болары – рухи хәерчелек коллары иде. Хикмәт бит акчада гына түгел, аны кая, нинди эшләргә тотуда.

Арчага барып, бер атна узгач, Азнакайга, Рөстәмнең туган авылы – Үчәллегә юл тоттым. Авыл уртасындагы клуб каршында Рөстәм Зәкуанов истәлегенә стела ачыласын ишеткән идем инде. Без Гөлфәния белән хәбәрләшеп яшибез, ул бер көн алдан авылга кайтасын, кунакларны каршы аласын әйтеп куйган иде. Шуның өстенә Азнакай хакиме Марсель Шәйдуллин имзасы белән редакциягә чакыру да килгән иде. Анда «хөрмәтле кунак буларак» мине көтеп калулары турындагы җөмлә янә уйга калдырды. Азнакайга кем буларак кайтам соң мин? Рөстәм исән чакта Азнакай юлларын бергәләп шактый еллар таптадык без. Аның белән сәфәр чыгу үзе бер рәхәт иде. Күңел капкаларын киереп ачып дигәндәй, тормыш, яшәү мәгънәсе турында рәхәтләнеп сөйләшә идек. Телендә гел эш иде аның, күңелдәге уйларын шигырь юлларына салырга вакыт таба алмый интекте. Шуңа күрә аның иҗаты соңгы елларда гына ургылып чыккандыр да. «Соңгы еллар» дигәнем аның Дәүсовет депутаты булып торган чорына кагыладыр, мөгаен. Депутатлыкны бик ошатмады ул. Аңа тотып эшли торган, кеше күзенә күренә торган эш кирәк иде. Әмма нәкъ шул елларда иҗат өчен вакыт табыла башлагандыр да инде. «Депутат эшен яратмады» дип яздым язуын, әмма Рөстәм «үз урыныннан файдаланып» авылларның гомерен озынайту өчен җиң сызганып эшкә керәште. Үчәлледә «Җәмәгать үзәге», ягъни клуб төзетүдә, өйләргә су кертүдә аның өлеше гаять зур булды. Стела кую тантанасына җыелган халык Рөстәмнең игелекләрен искә төшереп, рәхмәт укыды.

Ә халык бик ишле иде әлеге тантанада. Район хакиме Марсель Шәйдуллин әйтүенчә, авыл Сабан туена да бу хәтле кеше җыелмый икән. Үзең нинди – дусларың шундый була инде ул. Рөстәм янына халык үзе килгән, чакыру-фәлән көтеп тормаган, аңа хөрмәт-ихтирам хисләрен белдерү, рәхмәт әйтү өчен җыелган.

Мәңгелектә яшәүнең бер галәмәте әнә шул халык күңелендә саклану була инде.

Мин Рөстәм Зәкуанның шагыйрь буларак иҗаты турында берни дә язып тормыйм. Аның 200ләп шигыре җырга салынганын әйтсәм, аңлаган кешегә аңларлык булыр. Атаклы Чатыртауга менгәндә «болытларны юрган итеп, яшел мендәргә баш кую»ны шигъри юлларга салган Рөстәм дус үзенең җырларында, шигырьләрендә дә яшәр әле.

Мин бүген аның тормыш юлын да язып тормыйм. Татарстан, аның халкы, авыллары яшәсен, милләт тарихы онытылмасын дип яшәүчеләр бездә артык күп түгелдер дип кенә әйтәсе килә. Рөстәм Зәкуан әнә шул сирәк шәхесләрнең берсе иде.

Азнакайдан кайткач, сабакташым, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров белән сөйләшеп алдым. Рөстәмне бик хөрмәт итүче егет ул Зиннур. Арчада, Азнакайда шагыйрь дустын хөрмәтләп искә алулары турында сөйләгәч, гыйбрәтле генә сүзләр әйтеп куйды. «Кешенең кылган барлык эшләре – яхшысы да, яманы да гамәл дәфтәренә язылып барыла. Рөстәмнең бер генә дәфтәре, изге гамәлләр дәфтәре генә бар дип уйлыйм. Мәңгелектә калу шул була инде ул», – диде.

Быел 25 майда Рөстәм Газизҗан улы Зәкуановка 65 яшь тулырга тиеш иде. Ни кызганыч, язмамда гел үткән заман фигыльләрен генә кулланырга туры килде.

Аның туган көне уңаеннан рәсми чаралар узмады. Бәлки, кирәге дә булмагандыр. Иң әһәмиятлесе, аны дуслары, хезмәттәшләре, авылдашлары, җыеп әйткәндә, халык үзе зурлады. Минемчә, бу – иң зур бәһа.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ТАБИГАТЬ ХАКЫНА

Бәйгедән соң

Татарстанда «Экояз» бәйгесенә нәтиҗә ясадылар. Ул 1 апрельдән 31 майга кадәр дәвам итте. Әлеге бәйге республикада җиденче тапкыр уздырыла. Вакытын да сайлый беләләр – чара санитар-чистарту икеайлыгы кысасында үткәрелә. Экологларның максаты да – күбрәк кешене табигатькә тарту, аларның күңелен үзгәртү, сакчыл булырга өйрәтү. Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков республика халкына рәхмәтле икәнен яшерми. Теләгәнебезгә ирешеп барабыз, ди ул.

– Бу залда бүген иң-иң яхшылары җыелды, – диде ул, җиңүчеләрне сәламләп. – Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча изге гамәлләр кылган кешеләр сез. Әлеге чара кемне генә үзенә ияртмәде. Гаиләләре, туганнары, урамнары, авыллары белән безгә кушылды. Шунысын да истән чыгармыйк: кеше табигатькә нинди мөнәсәбәттә булса, тирә-ягындагы кешеләргә шундый була. Туган җирен яраткан, аны кадерләп тоткан кеше башкаларны да хөрмәт итә. Үзебез, балаларыбыз яшәгән җирне без бәйге вакытында гына түгел, һәркөнне чистартырга тиеш. Бүген исә мин «Экояз» бәйгесендә катнашкан һәр кешегә чиксез рәхмәтемне белдерәм.

Министр сүзләренчә, быел икеайлык кысасында үткәрелгән чараларда 755 мең кеше катнашкан. Полигоннарга 510 мең кубометр калдык чыгарылган. Республика районнарында – 760 мең, предприятие-оешмалар 540 мең төптән артык агач һәм куак утыртылган.

– Ике ай эчендә табигать саклау законнарын бозуның 7 мең очрагы ачыкланып, 3,3 мең бозучы административ җаваплылыкка тартылды. Республикада 3,8 мең рөхсәтсез калдык ташлау урыны бетерелде, – ди Александр Шадриков.

«Экояз» бәйгесендә җиңүчеләрне «Иң яхшы балалар бакчасы», «Иң яхшы мәктәп», «Иң яхшы гаилә», «Иң яхшы предприятие», «Иң яхшы ишегалды», «Иң яхшы массакүләм мәгълүмат чарасы» номинацияләрендә билгеләделәр. «ВТ» хәбәрчесе «Иң яхшы гаилә» дип табылган Шәйхәйдәровлар белән дә сөйләште. Алар Кама Тамагы районының Антоновка авылында яши. Ренат белән Айгөл дүрт бала үстерә, бишенчесен көтәләр. Алар 2011 елдан бирле авылларын яшелләндерә. 11 ел эчендә 100 гектар мәйданда 50 меңнән артык агач утыртканнар. Казаннан күченеп кайтуларына 11 ел икән.

– Башта урманчыларга ярдәм итик дип агач утырта башладык. Аннары бу эшебез үзебезгә дә ошап китте. Дуслар белән бергә, төрле чаралар уздырып, агач утырта башладык. Без бик күңелле яшибез. Авылыбызда төрле бәйрәмнәр дә еш уза. Күбрәк җырлар җырлыйбыз. Эшлибез дә, ял да итә беләбез, – ди Айгөл Шәйхәйдәрова. – Бездә пихта, миләш, кедр, карагай, алма, карлыган үсә. Аю чикләвеге белән дала миндале дә утыртып карадык. Кәлшәләрне үзебез дә үстерәбез, питомниклардан да алабыз. Табигатькә бәйле барлык чараларда актив без. Идел буен чүп-чардан чистартабыз, авылда уздырылган өмәләрдә катнашабыз.

Ире Ренат исә авылда яшәүнең рәхәтлекләрен санап бетерә алмый. Киләчәктә яшьләрне авылга кайтару нияте белән яши ул. Шәһәрдә үскән хатыны да авылны бик яраткан.

– Безнең өчен бүләк түгел, агачларның шаулап үсүе әһәмиятлерәк. Аларны күреп күңел сөенә. Җиңгәч, сөендек инде. Тагын да бәйгеләрдә катнашырга икән дигән теләк тә уянды. Катнашу балаларга кирәк ул. Алар белеп үссен, чүпләмәсен. Балалар – безнең киләчәк бит, – ди ул.

Ни өчен шәһәрне ташлап авылга кайтырга булган соң алар? Шул хакта да сорадык. Гаилә бу адымнарын җирсү белән бәйләп аңлатты. Баксаң, Антоновкада Ханты-Манси, Санкт-Петербург һәм башка шәһәрләрдән дә күченеп кайтып яшиләр икән.

Санкт-Петербург дигәннән, Шәйхәйдәровлар озакламый шушы шәһәргә юл тотачак. «Экояз» бәйгесендә беренчелекне алган өчен аларны юллама белән бүләкләделәр. Гаилә бишенче балалары дөньяга килгәнче шәһәр күреп кайтырга ниятли.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 282

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт. График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+